**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ ПР-292 23 ноябрь, 2018 ел

«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршында яшьләр белән системалы эш алып бару буенча иҗтимагый координация үзәген оештыру турында» Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 09 февралендәге ПР-15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру, яшьләр белән, шул исәптән ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә, оешмаларда һәм предприятиеләрдә тәрбия, экстремистлыкка каршы эш алып бару максатыннан, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 09 февралендәге ПР-15 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы яшьләр белән системалы эш буенча иҗтимагый координация үзәге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктның 4 абзацында «район максатчан» сүзләрен «муниципаль» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Үзәк әгъзалары була алмый:

- Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт вазыйфаларын, Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар;
- суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган затлар;
- кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган затлар;
- -икеләтә гражданлыгы булган затлар.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Ш.Бариев